ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «17» мартыннан № 71

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары исемлеге турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары исемлеген расларга.

2. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары реестры формасын расларга.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының халык иҗаты һәм көнкүреше туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесенә кушымтада бирелгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары реестрын алып баруны йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының

җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары исемлеге турында» 2022 елның 01 апрелендәге 107 номерлы карарын (2023 елның 11 маендагы 127 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «17» мартындагы
71 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары исемлеге

| № т/б | Объект исеме | Объектның барлыкка килү вакыты | Урнашкан урынының адресы | Объектның төре | Аеруча кыйммәтле объект |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәүдә лавкасы бинасы | XIX гасыр ахыры | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Рус Чабаксары авылы, Елга урамы, 8а йорт | Һәйкәл | юк |
| 2 | «Югары Никиткино», «Тубылгытау», «Изгеләр», кабер ташлары белән (җиде) «Святые» зиратлары | XIV гасырның 1 нче яртысы | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Тубылгы Тау авылы | Һәйкәл | юк |
| 3 | Казан-Оренбург тракты күпере | 1909 ел | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Зирекле авылы, Ленин урамы | Һәйкәл | юк |
| 4 | Троицк чиркәве | 1875-1883 еллар | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Екатерина Бистәсе авылы, Үзәк урам | Һәйкәл | юк |
| 5 | Изгеләштерүче Николай Чудотворец гыйбадәтханәсе | 1875-1883 еллар | Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Рус Чабаксары авылы, Елга урамы | Һәйкәл | юк |
| 6 | Петропавловск | 1885 ел | Татарстан | | юк |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | чиркәве | | Республикасы, Яңа Чишмә районы, Петропавел Бистәсе авылы, 32 нче йорт | Һәйкәл | |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «17» мартындагы
71 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының
җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары
реестры формасы

| № т/б | Объектның исеме | Объектның барлыкка килү вакыты | Урнашкан урынының адресы | Объектның тасвирламасы | Фото (график) сурәтләр | Объектның төре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |